СОВЕТ УРМАНЧЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.5, п.Зверосовхоза,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРМАНЧЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Ленин ур., 5 нче йорт, Җәнлек совхозы поселогы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422186

тел.(факс): (85563) 2-12-50; e-mail: Urman.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Решение** **Карар**

№ 1-23 26 май 2017 ел

Урманчы авыл җирлеге Советының Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге территориясендә торак пункт төзү, аңа «Тарасово» исеме һәм поселок статусы бирү турындагы мәсьәләне инициативалау турындагы тәкъдимен кертү хакында.

Тарасово поселогы халкының 2017 елның 22 маендагы халык җыенында әйтелгән тәкъдимен гамәлгә ашыру максатында, «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында», 2005 елның 07 декабрендәге 116 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Урманчы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Урманчы авыл җирлеге Советының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге территориясендә торак пункт төзү, аңа «Тарасово» исеме һәм поселок статусы бирү турындагы мәсьәләне инициативалау турындагы тәкъдимен Мамадыш муниципаль районы Советына кертергә.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советының 2012 елның 18 гыйнварындагы 1-15 номерлы карарын үз көчен югалтты дип танырга.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталы (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Урманчы авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /Ильин А.Я.

СОВЕТ УРМАНЧЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ